**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«11» ноябрь, 2019 ел Түбән Суык-Су № 23

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә.

## КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 22 ноябренә 11.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы Заречная, Маҗын, Остров, Мәктәп, 8 Март, Үзәк урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Түбән Суык-Су авылы, Үзәк урамы, 1А йортында билгеләргә.
2. 2019 елның 22 ноябренә 15.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы Дуслык, Яшлек, Яр буе, Яңа, Яңа басу, Төзелеш, Юнусова, Парк, Камышлы урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Түбән Суык-Су авылы, Үзәк урамы, 1А йортында билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, Түбән Суык-Су авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум